**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №124-21 2023 елның "18" апреленнән

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 24 апрелендәге 168-42 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының карарына үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 16 июнендәге 181-43 номерлы, 2020 елның 24 августындагы 187-44 номерлы, 2020 елның 22 октябрендәге 12-2 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 19-3 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 33-8 номерлы, 2022 елның 12 октябрендәге 101-18 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2020 елның 24 апрелендәге 168-42 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (16.06.2020 елның 181-43 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:
«11) аларга чит ил агенты статусы алу. »;

1.2. 13 пунктта:

13.3 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

13.8 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

13.9 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) » сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 19.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:
«4) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу. "

1.4. 2 нче кушымтаның 2 бүлегенең 11, 12 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Раисе) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин